**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы составына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре һәм вазыйфаларының атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы ПУ-21 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 3 февралендәге ПУ-52 номерлы, 2004 елның 8 октябрендәге ПУ-613 номерлы, 2006 елның 25 ноябрендәге ПУ-504 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-541 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-206 номерлы, 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-704 номерлы, 2011 елның 26 мартындагы ПУ-154 номерлы, 2015 елның 28 мартындагы ПУ-370 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-25 номерлы һәм 2017 елның 21 октябрендәге ПУ-941 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Н.В. Фоминаны чыгарырга;

б) Совет составына Гомзик Илья Александровичны – Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы урынбасарын кертергә;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Х. Әюпованың – «Татарстан Республикасы мәдәният министры»;

Р.И. Вәлиевнның – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе (килешү буенча)»;

И.Р. Миңнуллинның – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары, тарих фәннәре кандидаты, Советның җаваплы секретаре (килешү буенча)»;

Р.Р. Салиховның – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Р.Р. Хәйретдиновның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры, тарих фәннәре кандидаты, Совет рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 17 июль
№ ПУ-586